ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге Советы

422741, ТР Әтнә муниципаль районы,
Түбән Көек авылы, Татарстан урамы, 71а
тел. 33-2-47

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Нижнекуюкского сельского поселения
Атнинского муниципального района

422741, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Нижний Куюк, улица Татарстан, 71а
тел. 33-2-47

**Карар № 103**

Түбән Көек авылы 21 апрель 2025 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының "Түбән Көек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2022 нче елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы федераль закон, "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында" 2024 елның 8 августындагы 232-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокурорының 2025 елның 31 гыйнварындагы 02-08-02-2025/прдп 14-25 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Көек авыл җирлеге Советының 2011 елның 29 мартында 15 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Түбән Көек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (29.08.2011 №23, 14.11.2011 № 26, 23.03.2012 № 30, 18.09.2012 № 40, 03.12.2012 № 44, 08.10.2013 №61, 23.03.2015 №96, 18.12.2015 №13, 02.05.2016 №26, 25.04.2017 №46, 28.08.2017 №53, 25.04.2018 №66, 21.12.2018 №82, 22.05.2019 №91, 03.10.2019 №101, 20.12.2019 №111, 09.03.2020 №118, 30.10.2020 №8, 29.01.2021 №15, 01.09.2021 №30, 18.07.2022 №45, 09.02.2023 №57, 29.09.2023 №79, 27.11.2024 № 93 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (кушымта нигезендә).

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге www.pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы: Галиәхмәтов Д.М.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге Советының 2025 елның 21
апрелендәге 103 номерлы
карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының "Түбән Көек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

**1.11 статьяның 7 пунктындагы 2 абзацны** түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:
«Җирле референдум Җирле үзидарә Советы тарафыннан билгеләнгән срокларда билгеләнмәгән очракта, референдум гражданнарның, сайлау берләшмәләренең, җирлек башлыгының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы Сайлау комиссиясенең яисә прокурорның мөрәҗәгате нигезендә суд тарафыннан билгеләнә. Суд тарафыннан билгеләнгән җирле референдум тиешле референдум комиссиясе тарафыннан оештырыла, ә аны уздыруны тәэмин итү Татарстан Республикасы башкарма органы яисә җирле референдум уздыруны тәэмин итү йөкләнгән башка орган тарафыннан гамәлгә ашырыла»;

**2.12 статьяның 3 пунктында** «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «тиешле сайлау комиссиясе яисә суд» сүзләренә алмаштырырга;

**3. 13 статьяның:**

5 пунктында «җирлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктында «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга, «сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктында «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

**4. 28 статьяның:**

2.3 пунктында:
«а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

«б» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» ("Татарстан Республикасы Премьер Министры") сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1 пунктында «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «башкарма органнары» сүзләренә алмаштырырга

6 пунктында «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктында «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

**5. 30 статьяның 1 пунктында** «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

**6. 31 статьяның 12 пунктын** төшереп калдырырга;

**7. 36 статьяның 3 пунктында** «җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориаль сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

**8. 38 статьяның:**

1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктча өстәргә:
«10.1) аларга чит ил агенты статусы алу;»;

8 пунктның 2 абзацында «(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

9. **43 нче статьяның 2 пунктының 2, 3 абзацларында** «(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен төшереп калдырырга;

**10. VII бүлекне төшереп калдырырга;**

**11. 57.1. статьяның:**

2 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү;».

2 пунктына түбәндәге эчтәлекле яңа пунктча өстәргә:

«7) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең эффектлылыгына бәя бирүдә системалы рәвештә күрсәткечләргә ирешмәү".